**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Муниципальное образование «Исполнительный комитет Урмандеевского сельского поселение» Аксубаевского муниципального района**


423053 село Савгачево,
улица Советская , 2а
☎(84344) 2-1431 факс 4-1431
E-mail: Urman.Aks@tatar.ru


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Муниципаль Берэмлеге «Урмандой авылы башкарма жирлек комитеты Аксубай муниципаль районы**


423053 село Савгачево,
улица Советская , 2а
☎(84344) 2-1431 факс 4-1431
E-mail: Urman.Aks@tatar.ru



**ИНН 1603004991 КПП 160301001 р/с 03231643926044901100 Банк: ГРКЦ НБ г. Казань ЛБ03922018-ИспКУрмСП**
**л/с 40116810402210040115 БИК 019205400 ОГРН 1061665003190**


**КАРАР**

22.10.2025 ел № 8

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Башкарма комитеты "Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 18.09.2024 елгы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 31.07.2025 елгы 304-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясындагы 3 пунктының г, д пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАРы:

1.Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Башкарма комитеты 18.09.2024 № 5 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктының 4 пунктчасында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк" сүзләрен "мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк"сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктында түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчасы өстәргә::

"4.1)Мөрәҗәгать итүче булмаган затның персональ белешмәләре бирелгән очракта, федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы аша мондый затның яисә аның шәхси белешмәләр эшкәртүгә законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда ризалыгын алу таләп ителми.""

2.Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы рәсми сайтына (http://aksubaevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан

Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3.Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: В.З.Николаев